КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 июль г.Казань № 903

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 июль, 703 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы; 2022 ел, 18 ноябрь, 1232 нче; 2023 ел, 27 гыйнвар, 59 нчы; 2023 ел, 27 март, 358 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктның алтынчы абзацында «һәм баш бухгалтеры» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.7 пунктның өченче абзацында «65» саннарын «47» саннарына алмаштырырга.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 30 ноябрь, 1271 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2023 ел, 27 гыйнвар, 59 нчы; 2023 ел, 27 март, 358 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктның алтынчы абзацында «һәм баш бухгалтеры» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.7 пунктның өченче абзацында «70» саннарын «47» саннарына алмаштырырга.

3. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин